КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 818

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 924 нче карары белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 924 нче карары белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктта:

беренче – икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Министрлык гаризалар кабул итә башлау датасына кадәр өч эш көне эчендә бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mert.tatarstan.ru) (алга таба - рәсми сайт) түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында игълан итүне урнаштыруны тәэмин итә:

сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

13 пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

унберенче абзацта «, максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

V бүлекнең исемендә «контроль» сүзен «контроль (мониторинг)» сүзләренә алмаштырырга, «, максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

18 пунктта «нәтиҗәгә ирешү турында хисап» сүзләрен «нәтиҗәнең мәгънәсенә ирешү турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

24 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 8 пунктындагы бишенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы унбишенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин